**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында» 2000 елның 24 маендагы ПУ-369 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «милиция инспекторлары» сүзләрен «полиция уполномоченныйлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

полиция участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына хезмәткәрләр әлеге вазыйфаларны биләгән чорда «Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә муниципаль торак фонды торак биналарын бирергә;

полиция участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына хезмәткәрләр әлеге вазыйфаларны биләгән чорда торак бина бирү тәртибен билгеләргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен үстерүне планлаштырганда тәртип саклау җәмәгать пунктлары төзүне һәм полиция участок уполномоченныйлары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары өчен, хезмәткәрләр әлеге вазыйфаларны биләгән чорда, муниципаль торак фонды булдыруны күздә тотарга;

җирле бюджетларда тәртип саклау җәмәгать пунктларын карап тотуга чыгымнарны күздә тотарга.»;

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетара мөнәсәбәтләрне

формалаштырганда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны күздә тотарга.»;

д) 6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 29 июль
№ ПУ-606